Өченче чакырылыш Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының егерме тугызынчы утырышы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы
карары

5 декабрь, 2019 ел № 236

Питрәч муниципаль районы территориясендә милләтара, конфессияара мөнәсәбәтләр һәм иҗтимагый-сәяси хәлнең торышы турында

Питрәч муниципаль районы территориясендә милләтара, конфессияара мөнәсәбәтләрнең торышы һәм иҗтимагый-сәяси куркынычсызлыкны тәэмин итү буенча бурычлар турындагы мәгълүматны тыңлаганнан соң, дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру, милләтара татулыкны һәм конфессияара татулыкны саклау, Питрәч муниципаль районы территориясендә тотрыклы социаль-сәяси вәзгыятьне тәэмин итү максатларында, **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Питрәч муниципаль районы территориясендә милләтара, конфессияара мөнәсәбәтләр һәм иҗтимагый-сәяси хәл торышы турындагы мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Питрәч муниципаль районы башкарма комитетына түбәндәге муниципаль программалар чараларының үтәлешен тәэмин итәргә:

- «2019-2023 елларга Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында Терроризм һәм экстремизмны профилактикалау һәм 2019-2023 елларга Россия Федерациясендә терроризм идеологиясенә каршы тору Комплекслы планы чараларын гамәлгә ашыру»;

- «2014-2020 елларга Питрәч муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру»;

3. Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф, мәдәният, яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлегенә компетенцияләр кысаларында эшне активлаштырырга:

- ведомство карамагындагы учреждениеләрдә, формаль булмаган иҗтимагый оешмаларда һәм берләшмәләрдә балалар һәм яшьләрнең радикальләшүенә каршы торуга юнәлтелгән профилактик чаралар үткәрү буенча;

- милли мәдәниятләрне саклау һәм үстерү, Питрәч муниципаль районы территориясендә яшәүче төрле милләт халыкларының бердәмлеген ныгыту буенча социаль-мәдәни өлкә учреждениеләре.

4. Авыл җирлекләре башлыкларына киңәш итәргә:

- Россия Эчке эшләр министрлыгының Питрәч районы буенча бүлеге белән берлектә чит ил гражданнарының һәм гражданлыгы булмаган затларның законсыз яшәү фактларын, законсыз хезмәт эшчәнлеген кисәтү, ачыклау һәм булдырмау буенча эшне дәвам итәргә;

- миграция хезмәте белән яшәү өчен яраксыз булган йортларда чит ил гражданнарын теркәү фактларын ачыклауга, чагыштыру уздыру һәм югарыда әйтелгән очракларны ачыклау буенча район прокуратурасына даими рәвештә чагыштыру үткәрергә;

- чит ил гражданнарына, шул исәптән хезмәт мигрантларына карата җирле халыкның кәефен системалы рәвештә анализларга;

- район руханилары белән даими элемтәдә торырга.

5. Әлеге карарны Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Питрәч муниципаль районы Советының социаль мәсьәләләр, сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният һәм яшьләр эшләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И. М. Кашапов